ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная площадь, д.1, с. Коргуза, 422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАРАГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагужа авылы, 422586

Тел.: (84379) 35-5-70, факс: (84379) 35-5-70.

11.12.2020 № 01

На № ______________ от ________________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авылы җирлегенең Егидерево авылында халык җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1нче, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясы нигезендә, 2020нче елның 11нче декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән: 2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авылы җирлегенең Егидерево авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме? дигән сорау буенча беркетмә төзелде:

- Егидерево авылында суүткәргечне ремонтлау;
- Егидерево авылында су башнясын ремонтлау.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 61 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 33 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 33 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Егидерево авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Егидерево авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән билгеләнгән гражданнарның ташламалы категориясеннән тыш, балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге

мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү, дигән сорау буенча карарны таныргa: - Егидерево авылында суүткәргечне ремонтлау;

- Егидерево авылында су башнясын ремонтлау.

3. Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Егидерево авылында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Карагуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге башлыгына адресларга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: С. А. Сакин